**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Мичән авыл җирлеге Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының вәкаләтләрен тапшыру турында килешү**

«26» февраль 2015 ел Байлар Сабасы ш.т.б.

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының башкарма комитеты, алга таба «Районның башкарма комитеты» дип аталучы Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы нигезләмә нигезендә эш итүче Гасимов Равил Мөбәрәк улы йөзендә, бер яктан, һәм Саба муниципаль районының Мичән авыл җирлеге Башкарма комитеты башлыгы йөзендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге Уставы нигезендә эш итүче Гәрәев Айзат Әхмәтгали улы, икенче яктан, алга таба «Яклар» дип аталучы, түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеделәр:

**1. Килешү предметы**

Әлеге Килешүнең предметы булып, район Башкарма комитеты тарафыннан җирлекнең Башкарма комитетына түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру тора:

– җирлектә яшәүчеләрне һәм аз керемле гражданнарның торак урыннарына мохтаҗларны торак урыннары белән тәэмин итү;

– торак төзелеше өчен шартлар тудыру;

– муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру;

– муниципаль торак фондын исәпкә алу;

– гражданнарны аз керемлеләр дип тану һәм аларга муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү максатларында гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган керем күләмен һәм гаилә әгъзалары милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү;

– гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип тану максатларында гражданнарның һәм алар белән бергә даими яшәүче гаилә әгъзаларының керемен һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтләренең хакын билгеләү;

– гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип тану максатларында гражданнарның һәм алар белән бергә даими яшәүче гаилә әгъзаларының кеременең һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтләре хакының максималь күләмен билгеләү;

– социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗлар буларак гражданнарны билгеләнгән тәртиптә исәпкә алуны алып бару;

– социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алуны алып бару;

– муниципаль торак фондының торак урыннарын социаль наем шартнамәләре буенча билгеләнгән тәртиптә аз керемле гражданнарга бирү;

– муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру;

– җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру һәм парковкалар (парковка урыннары) төзүне һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итүне дә кертеп, аларда юл хәрәкәте куркынычсызлыгын тәэмин итү;

– җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;

– гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юллары исемлеген, гомуми булмаган файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юллары исемлеген раслау.

**Якларның хокуклары һәм бурычлары**

2.1. Районның Башкарма комитеты авыл җирлеге Башкарма комитетына түбәндәгеләрне бирергә тиеш:

әлеге Килешү нигезендә тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс чаралары һәм матди ресурслар (алга таба-вәкаләтләр);

вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүмат.

2.2. Район Башкарма комитеты түбәндәге хокукларга ия:

җирлекнең Башкарма комитеты тарафыннан вәкаләтләр үтәлешен, шулай ук бирелгән финанс чараларыннан максатчан файдалануны әлеге Килешүнең 5.1-5.3 пунктларында билгеләнгән тәртиптә тикшереп торырга;

җирлек Башкарма комитетыннан әлеге Килешү предметына кагылышлы мәгълүматны алырга.

2.3. Җирлекнең Башкарма комитеты түбәндәгеләргә бурычлы:

законнар таләпләре нигезендә вәкаләтләрне гамәлгә ашырырга, шул исәптән районның Башкарма комитеты тарафыннан бирелгән финанс чараларыннан максатчан файдалануны фәкать вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга тәэмин итәргә;

вәкаләтләрнең үтәлеше турында квартал саен район башкарма комитетына, шулай ук Килешү предметына кагылышлы башка төрле мәгълүмат тапшырырга.

2.4. Җирлекнең Башкарма комитеты түбәндәгеләргә хокуклы:

вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен районның Башкарма комитеты тарафыннан тапшырыла торган финанс чараларын алырга һәм кулланырга;

Башкарма комитеттан вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны соратып алырга;

вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен законнар нигезендә башка матди ресурслардан һәм финанс чараларыннан өстәмә файдаланырга.

**3. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен финанс чаралары бирү тәртибе**

3.1. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс чаралары бюджет законнары нигезендә ел саен Саба муниципаль районы бюджетыннан Саба муниципаль районының Мичән авыл җирлеге бюджетына бирелә торган субвенцияләр рәвешендә бюджетара трансфертлар юлы белән бирелә.

3.2. Яклар ел саен тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле субвенцияләр күләмен билгели.

3.3. Саба муниципаль районы бюджетыннан әлеге Килешүнең 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга авыл җирлеге бюджетына бирелә торган субвенцияләрне формалаштыру, санап чыгару һәм исәпкә алу Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.4. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бирелә торган финанс чаралары, кагыйдә

буларак, ай саен тигез өлешләр белән күчерелә, әмма финанс чараларының бөтен суммасын бер үк вакытта күчерергә дә мөмкин.

3.5. Җирлекнең Башкарма комитеты финанс чараларын максатчан файдаланмаган очракта, алар район Башкарма комитеты таләбе буенча ун көн эчендә район бюджетына кайтарылырга тиеш.

**4. Матди ресурсларны тапшыру тәртибе.**

4.1. Муниципаль милекне түләүсез файдалану шартнамәсе нигезендә, вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәк булганда, район Башкарма комитеты тапшыра, ә җирлек Башкарма комитеты кабул итә.

4.2. Әлеге Килешүнең 4.1 пунктында күрсәтелгән түләүсез файдалану шартнамәсе ашыгыч рәвештә төзелә һәм әлеге Килешүнең гамәлдә булу чорына төзелә.

4.3. Әлеге Килешүнең 4.1 пункты нигезендә бирелгән матди ресурслардан файдалану тәртибе түләүсез файдалану шартнамәсе белән билгеләнә һәм аның мөһим шарты булып тора.

**5. Вәкаләтләрнең үтәлешен тикшереп тору**

5.1. Районның Башкарма комитеты вәкаләтләрнең үтәлешен тикшерә, җирлек башкарма комитетыннан тапшырылган финанс чараларыннан һәм матди ресурслардан файдалану турында кирәкле мәгълүмат соратып ала. Җирлекнең башкарма комитеты район башкарма комитеты соратып алган мәгълүматны бирергә һәм аның вәкилләренең тикшерелә торган объектларга керүен тәэмин итәргә тиеш.

5.2. Хисапларның рәвеше һәм аларны бирү тәртибе район Башкарма комитетының хокукый актлары белән билгеләнә.

5.3. Тапшырылган финанс чараларын һәм матди ресурсларны тотуны тикшереп тору Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының контроль-хисап палатасы тарафыннан, шул исәптән район Башкарма комитеты таләбе буенча да, гамәлгә ашырыла.

**6. Килешүнең гамәлдә булу вакыты**

6.1. Килешү Яклар тарафыннан имзаланган көннән үз көченә керә һәм 2015 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

6.2. Әлеге Килешүнең гамәлдә булуы 2015 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6.3. Килешү, әгәр Якларның берсе дә аны өзү турында әлеге Килешүнең 6.1 пунктында каралган срок тәмамланырга 30 көннән дә соңга калмыйча белдермәсә, 2016 елга озайтылган дип санала.

**7. Килешүне вакытыннан алда туктату нигезләре һәм тәртибе**

7.1. Әлеге Килешү гамәлдә булу вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

– Яклар килешүе буенча;

– Якларның берсе үз йөкләмәләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта, берьяклы тәртиптә.

7.2. Әлеге Килешүне өзү турында хәбәрнамә башка Якка язма рәвештә, аның гамәлдә булу фаразланган датага кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча җибәрелә.

7.3. Әлеге Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылган очракта, җирлек башкарма комитеты район башкарма комитетына вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен тапшырылган файдаланылмаган финанс чараларын һәм матди ресурсларны,

мөлкәтне кире кайтара.

**8. Якларның җаваплылыгы**

8.1. Әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү законнарда каралган җаваплылык барлыкка килүгә нигез булырга мөмкин..

8.2. Якларның берсе әлеге Килешү буенча үз йөкләмәләрен үтәмәгән өчен гаепле Як башка Якка әлеге Килешүнең 3.2 пунктында каралган финанс чаралары күләменең 0,1 проценты күләмендә штраф сала.

8.3. Штраф түләү якларны әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне алга таба үтәүдән азат итми.

**9 маддә Бәхәсләрне хәл итү тәртибе**

Әлеге Килешүне гамәлгә ашыру белән бәйле бәхәсләр сөйләшүләр һәм башка килештерү гамәлләре юлы белән хәл ителә.

Бәхәсне сөйләшүләр яки килештерү процедураларын үткәрү юлы белән хәл итү мөмкин булмаган очракта, ул законнарда каралган башка тәртиптә каралырга тиеш.

**10. Йомгаклау нигезләмәләре**

10.1. Килешүгә кертелгән барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр Якларның үзара ризалыгы белән кертелә һәм язма рәвештә өстәмә Килешү белән рәсмиләштерелә. Өстәмә Килешүләр әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора.

10.2. Килешү һәр ике як өчен дә тигез юридик көчкә ия булган ике нөсхәдә төзелде.

**11. Якларның имзалары**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты
Җитәкчесе
_________________ Р.М.Гасимов
______________________

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Саба муниципаль районы
Мичән авыл җирлеге
Башлыгы
_________________ А.Ә. Гәрәев